**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**Сарлинского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл жирлеге БАШЛЫГЫ**

ул. Центральная, д. 68А, село Сарлы
Азнакаевского муниципального района, 423315
Тел. 36-5-34

Үзәк урам, 68А, Сарлы авылы
Азнакай муниципаль районы, 423315
Тел. 36-5-34

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11 ноябрь 2025 ел №2

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Сарлы торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сарлы авыл җирлеге Уставы нигезендә, **карар итәм**:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Сарлы авылында 2026 елда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын ТР, Азнакай муниципаль районы, Сарлы авылы, Узәк ур., 68А адресы буенча урнашкан Сарлы авылы мәдәният йорты бинасында 2026 елның 21 ноябрендә 10.00 сәгатькә билгеләргә.

2.Билгеләү:

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлегенең Сарлы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге башкарма комитеты;

- гражданнар җыенын үткәрү вакыты-2025 елның 21 ноябре 10.00 сәгатьтән 11.00 сәгатькә кадәр;

– халык җыенын үткәрү урыны- Сарлы авылы, Узәк ур., 68А йорт, Сарлы авылы мәдәният йорты залы

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сарлы авыл җирлеге башкарма комитетына тәкъдим итәргә.:

2025 елның 11 ноябреннән дә соңга калмыйча гражданнарга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сарлы авыл җирлеге Башкарма комитетында түбәндәге адрес буенча гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын тәэмин итәргә: Сарлы авылы, Узәк ур., 68А йорты;

Сарлы торак пунктында сайлау хокукына ия халык исемлекләрен төзергә;

гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

Сарлы торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлегенең Сарлы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы тыл хезмәтчәннәреннән, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, махсус хәрби операцияләрдә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларына (әни, әти), Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узучы гражданнарга бер тапкыр түләүне 2 һәм 3 төркем инвалидларга 250 сум күләмендә билгеләп һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп киметергә:

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү автомобилен йөртүченең хезмәтенә түләү, резервуарларга, янгын сүндерү автомобиленә запас частьләр сатып алу);

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (электр товарлары сатып алу, урам яктырткычларын һәм лампаларын алыштыру, урам яктырткычларын ремонтлау, аларга хезмәт күрсәтү хезмәтләре күрсәтү);

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (юлларны һәм территорияләрне кардан чистарту, үлән чабу, чүп җыюда трактор йөртүченең хезмәтләре өчен түләү);

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту(чокырларны асфальт белән ремонтлау)..

«КАРШЫ» «РИЗА»

5.Әлеге карарны Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Сарлы авылы, Узәк ур., 68А йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.;

Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru;

«Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

6.Әлеге карар халыкка игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Председатель САРЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ САРЛИНСКИЙ СОВЕТ СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ И.М.Камалетдинов